# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 30 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 21 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта "тәэмин итүне" сүзләреннән соң "Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә" сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) җирлектә яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;";

в) 20 пунктта "муниципаль төзелешне" сүзләрен "төзелешне" сүзенә алмаштырырга, "җир контролен гамәлгә ашыру" сүзләрен "муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру" сүзләренә алмаштырырга;

2) $15^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге

181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә.";

3) 16 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында "тәэмин итүне" сүзләреннән соң "Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә" сүзләрен өстәргә;

4) $16^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 10 пункт өстәргә:

"10) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә;";

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында" 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гамәлләрне башкаруга.";

5) 17 статьяның 1 өлешендә:

а) 4 пунктта "тәэмин итүне" сүзләреннән соң "Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә" сүзләрен өстәргә;

б) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) шәһәр округында яшәүче һәм торак урыннарына мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, муниципаль торак контролен, шулай ук торак законнары нигезендә җирле үзидарә органнарының бүтән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру;";

в) 26 пунктта "муниципаль төзелешне" сүзләрен "төзелешне" сүзенә алмаштырырга, "җир контролен гамәлгә ашыру" сүзләрен "муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру" сүзләренә алмаштырырга;

6) $17^1$ статьяның 1 өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук "Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында" 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның бөтенроссия җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтүгә;";

б) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

"12) "Кан һәм аның компонентлары донорлыгы турында" 2012 елның 20 июлендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гамәлләрне башкаруга.".

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының "б" пунктчасыннан һәм 6 пунктының "б" пунктчасыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктының "б" пунктчасы һәм 6 пунктының "б" пунктчасы 2013 елның 27 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2012 елның 12 ноябре
№ 76-ТРЗ